Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы

# КАРАР

«16» декабрь, 2025 ел №11

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җирлек башлыгы Ф.М. Фәттахов

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 2025 елның «16»декабрендәге 11 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында НИГЕЗЛӘМӘ

## I бүлек ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 1 статья. Әлеге Нигезләмә белән җайга салына торган хокук мөнәсәбәтләре

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Салым кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге (алга таба – җирлек) Уставы нигезендә җирлек бюджетын төзү, карау, раслау, үтәү һәм аның үтәлешен тикшереп тору барышында, шулай ук бурычларны гамәлгә ашыру һәм җирлекнең муниципаль бурычы белән идарә итү барышында бюджет хокук мөнәсәбәтләре субъектлары арасында барлыкка килә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала.

### 2 статья. Җирлектә бюджет хокук мөнәсәбәтләрен гамәлгә ашыруның хокукый нигезләре

Җирлектә бюджет хокуклары Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы бюджет законнарының һәм җирлекнең вәкиллекле органының башка актлары, әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 3 статья. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр һәм терминнар

Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе Бюджет кодексы билгеләгән мәгънәләрендә кулланыла.

## 4 статья. Җирлек бюджетының хокукый формасы

Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге бюджеты (текстта алга таба – җирлек бюджеты) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы (алга таба текст буенча – җирлек Советы) карары рәвешендә эшләнә һәм раслана.
Җирлек бюджеты өч елга – чираттагы финанс елына һәм план чорына төзелә һәм раслана.
Җирлек бюджеты проектын формалаштыру Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм җирлек Советының аның таләпләрен үтәп кабул ителә торган хокукый актлары нигезендә Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма комитеты (текстта алга таба – җирлек Башкарма комитеты) билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.
Җирлек Советының җирлек бюджеты турындагы карары чираттагы финанс елының 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм, әгәр җирлек бюджеты турындагы карарда башкасы каралмаган булса, финанс елының 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

## 5 статья. Бюджет классификациясен куллану үзенчәлекләре

1. Җирлек бюджетын төзү һәм үтәү, бюджет хисаблылыгын төзү Россия Федерациясендә билгеләнгән бюджет классификациясе нигезендә гамәлгә ашырыла.
2. Бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеге, аларга беркетелә торган бюджет керемнәре төрләре (төрчәләре) җирлек Советының җирлек бюджеты турындагы карары белән раслана.
Җирлек бюджеты акчаларын төп бүлүчеләр исемлеге җирлек Советының чыгымнарның ведомство структурасы составындагы җирлек бюджеты турындагы карары белән билгеләнә.
Бюджет чыгымнары төрләренең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) исемлегебюджет чыгымнарының ведомство структурасы составында җирлек Советының җирлек бюджеты турындагы карары белән йә Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән очракларда җыелма бюджет язмасы белән раслана.
Бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге җирлек бюджеты турындагы карар белән раслана.
Бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының статьялары һәм төрләре исемлеге, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын раслаганда, җирлек Советының җирлек бюджеты турындагы карары белән раслана.

## 6 статья. Бюджет процессы принциплары

Җирлектә бюджет процессы Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән Россия Федерациясе бюджет системасы принципларына нигезләнә:
- Россия Федерациясе бюджет системасының бердәмлеге;
- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәр, чыгымнар һәм бюджет кытлыкларын финанслау чыганакларын бүлү;
- бюджетларның мөстәкыйльлеге;
- Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең бюджет хокукларының тигезлеге;
- керемнәр, чыгымнар һәм бюджет кытлыкларын финанслау чыганаклары чагылышының тулылыгы;
- бюджетның балансчылыгы;
- бюджет акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге;
- бюджет чыгымнарын гомуми (җыелма) каплау;
- үтә күренмәлелек (ачыклык);
- бюджетның дөреслеге;
- бюджет акчаларының адреслылыгы һәм максатчан характеры;
- бюджет чыгымнарының ведомство буйсынуы;
касса бердәмлеге;
- бюджет процессында гражданнарның катнашуы

## 7 статья. Җирлекнең бюджет процессының төп этаплары

Җирлектә бюджет процессы түбәндәге этапларны үз эченә ала:
- җирлекнең социаль-икътисадый үсеше фаразын, бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләү;
- җирлек бюджеты проектын төзү;
- Гавами тыңлаулар турындагы нигезләмә нигезендә җирлек бюджеты проекты һәм җирлек бюджеты үтәлеше турындагы хисап буенча гавами тыңлаулар үткәрү;
- җирлек бюджетын карау һәм раслау;
- җирлек бюджетын үтәү;
- җирлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;
- муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру.

## 8 статья. Бюджет процессында катнашучылар

Җирлекнең бюджет процессында катнашучылар:
- Җирлек советы;
- Җирлек башлыгы;
- Җирлек башкарма комитеты
- җирлекнең финанс органы;
- Район Финанс-бюджет палатасы;

- Районның контроль-хисап палатасы;
- җирлек бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр (бүлүчеләр);
- бюджет акчаларын алучылар;
- бюджет керемнәренең баш администраторлары (администраторлары);
- бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары);
- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль хокукый актлар белән бюджет вәкаләтләре йөкләнгән башка органнар.

## 9 статья. Җирлекнең бюджет процессында катнашучыларының бюджет вәкаләтләре

1. Җирлек советы:
- җирлек бюджетын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны карый һәм раслый,
- үз утырышларында, комиссияләр, эшче төркемнәр утырышларында,җирлек Советы үткәргән тыңлаулар барышында һәм депутат запрослары белән бәйле рәвештә, җирлек бюджеты үтәлешенең аерым мәсьәләләрен карау барышында контрольне гамәлгә ашыра,
- тышкы муниципаль финанс контроле органнарының хокукый статусын формалаштыра һәм билгели,
- башка вәкаләтләрне Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, җирлек уставы, әлеге Нигезләмә белән.
2. Җирлек башлыгы:
- җирлек Советының җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүне, үзгәртүне һәм юкка чыгаруны, җирле салымнар буенча салым ташламаларын кертүне, җирлек бюджетыннан чыгымнарны гамәлгә ашыруны күздә тоткан норматив хокукый актларына бәяләмәләрне раслый;
- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, җирлек уставы, әлеге Нигезләмә нигезендә башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.
3. Җирлек башкарма комитеты:
- җирлекнең социаль-икътисадый үсеше фаразын төзүне оештыра, җирлек бюджеты проектын төзүне тәэмин итә;
-җирлекнең бюджет проектын төзү тәртибен һәм вакытларын билгели;
- кирәкле документлар һәм материаллар белән бергә җирлек бюджеты проектын җирлек Советы каравына кертә;
- җирлек Советына расларга бюджет үтәлеше турында хисап бирә;
- җирлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проектларын җирлек Советы каравына кертә;
- җирлек бюджетының үтәлешен һәм бюджет хисаплылыгын төзүне тәэмин итә;
- муниципаль бурычларны гамәлгә ашыру, муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү һәм аның белән идарә итү тәртибен раслый;

- муниципаль бурыч китабына кертелә торган Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнмәгән мәгълүмат составын, аны муниципаль бурыч китабына кертү тәртибен һәм вакытын билгели;
- муниципаль гарантияләр бирү тәртибен раслый;
- бюджет проектын (бюджет проектын һәм уртача сроклы финанс планын) төзүне тәэмин итә;
- бюджетара трансфертларны бүлү методикаларын һәм (яисә) бирү тәртипләрен эшли һәм раслый;
- муниципаль бурыч белән идарә итүне тәэмин итә;
- Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, җирлек Уставы, әлеге Нигезләмә нигезендә башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

4. Җирлекнең финанс органы:
- җирлек бюджеты проектын (җирлек бюджеты һәм уртача сроклы финанс планы проекты) төзүне оештыра һәм турыдан-туры төзи һәм аны җирлек Башкарма комитетына тапшыра;
- җирлек бюджетын үтәүне оештыра;
- бюджет хисаплылыгын төзү тәртибен билгели;
- җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап төзи;
- муниципаль бурыч китабын тутыра,
- бирелгән гарантияләрне, алар буенча муниципаль бурычны арттыруны, принципаллар йә өченче затлар тарафыннан гарантияләр белән тәэмин ителгән принципаллар йөкләмәләрен тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлештә үтәү нәтиҗәсендә муниципаль бурычны кыскартуны, башка нигезләр буенча гарантияләр белән тәэмин ителгән принципаллар йөкләмәләрен тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлештә туктатуны, бирелгән гарантияләр буенча, шулай ук муниципаль гарантияләр белән билгеләнгән башка очракларда гарант тарафыннан түләүләр башкарылуның исәбен алып бара;
- җыелма бюджет язмасын төзи һәм алып бара;
- җирлеккә карата дәгъвалар буенча суд актларын Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә үти;
- башкару документларын һәм аларны үтәүгә бәйле башка документларны исәпкә ала һәм саклый;
- Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджет законнарының башка актлары нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә норматив актлар кабул ителә;
- әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексында башкасы билгеләнмәгән булса, җирлек бюджеты чыгымнарының максатчан статьялары исемлеген һәм кодларын билгели;
- Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, әлеге Нигезләмә нигезендә башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

5. Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җирлекнең финанс органы вәкаләтләрен яисә вәкаләтләрнең бер өлешен җирлек

башкарма комитеты белән Кукмара муниципаль районының Башкарма комитеты арасындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырырга мөмкин.

6. Кукмара районының Контроль-хисап палатасы җирлекнең муниципаль финанс контроле органы вәкаләтләрен яисә вәкаләтләрнең бер өлешен килешү нигезендә башкарырга мөмкин.

7. Бюджет акчаларын баш бүлүче:

- аңа расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә бюджет акчаларын файдалануның нәтиҗәлелеген, адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә;
- үз карамагындагы бюджет акчаларын бүлүчеләрнең һәм алучыларның исемлеген төзи;
- аңа расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә үтәлергә тиешле чыгым йөкләмәләре реестрын алып бара;
- бюджетның тиешле чыгымнарын планлаштырны гамәлгә ашыра, бюджет ассигнованиеләрен нигезләүне төзи;
- бюджет язмасын төзи, раслый һәм алып бара, бюджет ассигнованиеләрен, бюджет йөкләмәләре лимитларын ведомство буйсынуындагы бюджет акчаларын бүлүчеләргә һәм алучыларга бүлә һәм бюджетның тиешле өлешен үти;
- бюджет йөкләмәләре лимитларын формалаштыру һәм үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;
- җыелма бюджет язмасын формалаштыру һәм үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;
- казна учреждениеләре булып торучы ведомство буйсынуындагы бюджет акчаларын алучыларның бюджет сметаларын раслау тәртибен билгели;
- муниципаль биремнәр формалаштыра һәм раслый;
- бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертларны, шулай ук Россия Федерациясе бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләрен алучылар тарафыннан аларны биргәндә билгеләнгән шартларны, максатларны һәм тәртипне үтәүне тәэмин итә;
- бюджет акчаларын баш бүлүченең бюджет хисабын төзи;
- муниципаль берәмлек исеменнән үзенә буйсынган бюджет акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләре буенча тиешенчә җавап бирә;
- «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында аларга капитал салуларны финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы булып федераль бюджет акчалары тора торган капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) турында белешмәләр төзи;
- Россия Федерациясе Бюджет кодексы, әлеге Нигезләмә һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

8. Бюджет акчаларын бүлүче:
- бюджетның тиешле чыгымнарын планлаштыруны гамәлгә ашыра;
- бюджет ассигнованиеләрен, бюджет йөкләмәләре лимитларын ведомство буйсынуындагы бюджет акчаларын бүлүчеләргә һәм (яки) алучыларга бүлә һәм бюджетның тиешле өлешен үти;
- үзе аның карамагында булган бюджет акчаларын баш бүлүчегә бюджет язмасын формалаштыру һәм үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;
- бюджет акчаларын тиешле баш бүлүче билгеләгән очракта һәм тәртиптә бюджет акчаларын үз карамагында булган баш бүлүченең аерым бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;
- бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертларны, шулай ук Россия Федерациясе бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләрен алучылар тарафыннан аларны биргәндә билгеләнгән шартларны, максатларны һәм тәртипне үтәүне тәэмин итә;
9. Бюджет акчаларын алучы:
- бюджет сметасын төзи һәм башкара;
- җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бюджет йөкләмәләрен кабул итә һәм (яисә) башкара;
- үзенә каралган бюджет ассигнованиеләрен куллануның нәтиҗәлелеген, максатчан характерын тәэмин итә;
- тиешле бюджет акчаларын баш бүлүчегә (бүлүчегә) бюджет язмасын үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;
- бюджет исәбен алып бара (бюджет исәбен алып баруны тәэмин итә);
- бюджет хисаплылыгын формалаштыра (бюджет хисаплылыгын формалаштыруны тәэмин итә) һәм бюджет акчаларын алучының бюджет хисабын тиешле бюджет акчаларын баш бүлүчегә (бүлүчегә) тапшыра;
- Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.
10. Бюджет керемнәренең баш администраторы:
- бюджет керемнәренең ведомство буйсынуындагы администраторлары исемлеген формалаштыра;
- бюджет проектын төзү өчен кирәкле белешмәләрне тапшыра;
- касса планын төзү һәм алып бару өчен белешмәләр тапшыра;
- бюджет керемнәре баш администраторының бюджет хисабын формалаштыра һәм тапшыра;
- Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.
11. Бюджет керемнәре администраторы:
- бюджетка түләүләрнең, аның буенча пенялар һәм штрафлар түләүнең дөреслеген, тулылыгын һәм үз вакытында башкарылуын исәпләү, исәпкә алу һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

- бюджетка түләүләр, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүне гамәлгә ашыра;
- бюджетына артык түләнгән (түләттерелгән) түләүләрне, пенялар, штрафларны шулай ук мондый кире кайтаруны үз вакытында башкармаган өчен процентларны һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентларны кире кайтару турында карар кабул итә, һәм ул, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кире кайтаруны гамәлгә ашыру өчен, Федераль казначылык органына йөкләмә бирә;
- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләрне исәпкә алу (төгәлләштерү) турында карар кабул итә һәм Федераль казначылык органына хәбәрнамә тапшыра;
- бюджет керемнәренең баш администраторы билгеләгән очракта һәм тәртиптә бюджет керемнәренең баш администраторына тиешле баш администратор вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләр һәм бюджет хисабын формалаштыра һәм тапшыра;
- РФ Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган норматив хокукый актларда (муниципаль хокукый актларда) билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.
12. Бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы:
- бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының үзенә буйсынучы администраторлары исемлекләрен формалаштыра;
- бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрне планлаштыруны (фаразлауны) гамәлгә ашыра;
- бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын түләү өчен аның карамагына бүлеп бирелгән ассигнованиеләрне куллануның адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә;
- бюджет ассигнованиеләрен бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының ведомство буйсынуындагы администраторларына бүлә һәм бюджетның тиешле өлешен үти;
- бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторының бюджет хисабын формалаштыра.
13. Бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары администраторы:
- бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрне планлаштыруны (фаразлауны) гамәлгә ашыра;
- бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының бюджетка керүенең тулылыгын һәм үз вакытында булуын контрольдә тота;
- бюджетка керүне һәм бюджеттан бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча түләүләрне тәэмин итә;
- бюджет хисабын төзи һәм тапшыра;
- бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының тиешле баш администраторы тарафыннан билгеләнгән очракта һәм тәртиптә үзе аның карамагында булган бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторының аерым бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар;

- РФ Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган норматив хокукый актларда (муниципаль хокукый актларда) билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

## 10 статья. Җирлек бюджеты керемнәре

Җирлек бюджеты керемнәре Россия Федерациясенең бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федарациясе законнары һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә формалаша.

## 11 статья. Керем чыганаклары реестры

1. Җирлекнең финанс органы җирлек бюджеты керемнәре чыганаклары реестрын алып бара.
2. Бюджет керемнәре чыганаклары реестры дигәндә җирлек бюджеты керемнәре чыганаклары буенча бюджетны төзү, раслау һәм үтәү процессында Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлеге нигезендә формалаштырыла торган бюджет керемнәре турындагы мәгълүмат җыелмасы аңлашыла.
3. Мәгълүмат составына, җирлек бюджеты керемнәре чыганаклары реестрын булдыру һәм алып бару тәртибенә карата гомуми таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.
4. Җирлек бюджеты керемнәре чыганаклары реестры җирлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә төзелә һәм алып барыла.
5. Җирлек бюджеты керемнәре чыганаклары реестрлары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә тапшырыла.

## 12 статья. Җирлек бюджеты чыгымнары

Җирлек бюджеты чыгымнарын формалаштыру федераль дәүләт хакимияте органнарының, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән, Россия Федерациясе законнары, халыкара һәм башка шартнамәләр һәм килешүләр буенча чираттагы финанс елында һәм план чорында җирлек бюджеты акчалары исәбеннән үтәлергә тиешле вәкаләтләрен бүлешүгә бәйле чыгым йөкләмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 13 статья. Башкарма комитетның резерв фонды

1. Җирлек бюджетының чыгым өлешендә Башкарма комитетның резерв фондын булдыру күздә тотыла.
2. Җирлек бюджетының чыгым өлешендә җирлек Советының резерв фондын төзү тыела.

3. Башкарма комитетның резерв фонды күләме җирлек Советының җирлек бюджеты турындагы карары белән билгеләнә һәм әлеге карар белән расланган чыгымнарның гомуми күләменең 3 процентыннан артмаска тиеш.
4. Башкарма комитетның резерв фонды акчалары көтелмәгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә, шул исәптән авария-торгызу эшләрен һәм табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле башка чараларны уздыруга, шулай ук әлеге статьяның 5 пунктында күрсәтелгән тәртиптә каралган башка чараларга җибәрелә.
5. Башкарма комитетның резерв фондының җирлек бюджеты составында каралган бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибе Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.
6. Башкарма комитет резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турындагы хисап җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка кушып бирелә.

## 14 статья. Муниципаль заказ

Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.
Товарлар китерүгә, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль заказ җирлек бюджеты акчалары исәбеннән түләнә.

## 15 статья. Чыгым йөкләмәләре реестры

1. Җирлекнең финанс органы җирлекнең чыгым йөкләмәләре реестрын алып бара.
2. Җирлекнең чыгым йөкләмәләре реестры җирлек башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә алып барыла.
3. Җирлекнең чыгым йөкләмәләре реестры җирлекнең финанс органы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырыла.

## 16 статья. Җирлекнең муниципаль бурычы структурасы

1. Җирлекнең бурыч йөкләмәләре түбәндәгеләр буенча йөкләмәләр рәвешендә булырга мөмкин:
1) җирлекнең кыйммәтле кәгазьләре (муниципаль кыйммәтле кәгазьләр);
2) Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җирле бюджетка җәлеп ителгән бюджет кредитлары;

3) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясеннән чит ил валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитлары;
4) җирлек тарафыннан кредит оешмаларыннан Россия Федерациясе валютасында җәлеп ителгән кредитлар;
5) Россия Федерациясе валютасында белдерелгән җирлек гарантияләре (муниципаль гарантияләр);
6) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясе чит ил валютасында бирелгән муниципаль гарантияләр;
7) Россия Федерациясе Бюджет кодексы гамәлгә кергәнче барлыкка килгән һәм муниципаль бурычка кертелгән бүтән бурыч йөкләмәләре буенча.
2. Муниципаль бурыч күләменә түбәндәгеләр кертелә:
1) муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча бурычның номиналь суммасы;
2) Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җирле бюджетка җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;
3) кредит оешмаларыннан җәлеп ителгән кредитлар буенча төп бурыч күләме;
4) муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме;
5) җирлекнең түләнмәгән бүтән бурыч йөкләмәләре күләме.
3. Муниципаль эчке бурыч күләменә түбәндәгеләр кертелә:
1) йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча бурычның номиналь суммасы;
2) йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җирле бюджетка җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;
3) йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән кредит оешмаларыннан җәлеп ителгән кредитлар буенча төп бурыч күләме;
4) Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме;
5) Россия Федерациясе валютасында түләнмәгән бүтән бурыч йөкләмәләре күләме.
4. Муниципаль тышкы бурыч күләменә түбәндәгеләр кертелә:
1) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясеннән җәлеп ителгән чит ил валютасындагы бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;
2) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында җирлек тарафыннан бирелгән чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме.
Җирлекнең бурыч йөкләмәләре кыска сроклы (бер елдан кимрәк), уртача сроклы (бер елдан биш елга кадәр) һәм озак сроклы (биш елдан 10 елга кадәр) булырга мөмкин.
5. Муниципаль бурыч китабын алып бару җирлекнең финанс органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.
Бурыч йөкләмәләре турында мәгълүмат "(Татарстан Республикасы муниципаль гарантияләре яисә муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләрдән тыш) муниципаль бурыч китабына йөкләмә барлыкка килгән вакыттан алып күп дигәндә биш эш көнендә кертелә.

6. Муниципаль бурыч кенәгәсенә әлеге йөкләмәләр төрләре буенча җирлекнең бурыч йөкләмәләре күләме, аларның барлыкка килү һәм тулысынча һәм өлешчә үтәлү (башка нигезләр буенча туктату) датасы, йөкләмәләрне тәэмин итү формалары турында белешмәләр, шулай ук составы, аны муниципаль бурыч кенәгәсенә кертү тәртибе һәм вакыты җирлек башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә торган башка мәгълүмат кертелә.
Җирлекнең муниципаль бурыч кенәгәсендә шул исәптән муниципаль бурыч йөкләмәләрен үтәү буенча кичектерелгән бурычлар турында мәгълүмат исәпкә алына.

**17 статья. Россия Федерациясе валютасында белдерелгән җирлекнең бурыч йөкләмәләрен туктату һәм аларны муниципаль бурычтан төшереп калдыру**

Әгәр Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль бурыч йөкләмәсе муниципаль бурыч йөкләмәләре шартларында каралган түләү датасыннан соң килүче датадан соң өч ел эчендә түләүгә куелмаган (кредитор тарафыннан билгеле бер шартлар һәм җирлекнең муниципаль хокукый актлары белән гамәл кылылмаган) булса, күрсәтелгән йөкләмә тулысынча туктатылган дип санала һәм, әгәр җирлек Советының вәкиллекле органының муниципаль хокукый актларында башкасы каралмаган булса, муниципаль бурычтан төшереп калдырыла.
Муниципаль гарантияләр буенча җирлекнең Россия Федерациясе валютасында бурыч йөкләмәләре муниципаль гарантияләрне туктатуга нигез булып торучы вакыйгалар (шартлар) туганда тулысынча туктатылган дип санала, һәм күрсәтелгән вакыйгалар (шартлар) башлану (килеп чыгу турында белешмәләр алу) белән муниципаль бурычтан төшереп калдырыла.
2. Җирле башкарма комитеты, әлеге статьяның 1 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән сроклар үткәннән соң, Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль бурыч йөкләмәләрен муниципаль бурычтан төшереп калдыру турында муниципаль хокукый акт чыгара.
3. Муниципаль бурычтан төшереп калдыру Россия Федерациясе валютасында белдерелгән төшереп калдырыла торган муниципаль бурыч йөкләмәләре төрләре буенча муниципаль бурыч күләмен, җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларында төшереп калдыру суммасын чагылдырмыйча гына, аларны төшереп калдыру суммасына киметү юлы белән гамәлгә ашырыла.
4. Әлеге статьяның 1 пунктындагы беренче абзацының, 2 һәм 3 пунктларының гамәлдә булуы кредит килешүләре буенча йөкләмәләргә, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм башка муниципаль берәмлекләр алдында муниципаль бурыч йөкләмәләренә кагылмый.
5. Муниципаль бурычтан реструктурлаштырылган, шулай ук түләнгән (сатып алынган) муниципаль бурыч йөкләмәләрен төшереп калдыру Россия Федерациясе Бюджет кодексының 105 һәм 113 статьялары нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

6. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне түләү датасы җиткәнчегә кадәр эмиссия шартлары нигезендә эмитацияләнгән орган тарафыннан тулы күләмдә сатып алынган (алмашу яисә Россия Федерациясе законнарында каралган башка операцияләр нәтиҗәсендә алынган) муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне чыгару күрсәтелгән орган карары буенча вакытыннан алда түләнгән дип танылырга мөмкин.
Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмитенты аларны түләү датасы җиткәнчегә кадәр сатып алынган (алмашу яисә Россия Федерациясе законнарында каралган башка операцияләр нәтиҗәсендә алынган) ул җитештергән муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча йөкләмәләрне үтәлгән дип танырга хокуклы.

## 18 статья. Муниципаль әҗәткә алулар

1. Җирлекнең муниципаль эчке бурыч алулары дигәндә муниципаль кыйммәтле кәгазьләр урнаштыру юлы белән һәм Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм кредит оешмаларыннан алар буенча җирлекнең Россия Федерациясе валютасында белдерелгән бурыч йөкләмәләре барлыкка килә торган кредитлар рәвешендә җирлек исеменнән җирле бюджетка заем акчаларын җәлеп итү аңлашыла.
2. Җирлекнең муниципаль тышкы бурыч алулары дигәндә, Россия Федерациясе тарафыннан максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында җирлек исеменнән федераль бюджеттан җирле бюджетка алар буенча җирлекнең Россия Федерациясе алдында чит ил валютасында белдерелгән бурыч йөкләмәләре барлыкка килә торган кредитлар җәлеп итүе аңлашыла.
3. Муниципаль тышкы бурыч алулар чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясенең Дәүләт тышкы бурыч алулары программасына кертелгән проектларны финанслау максатларында гамәлгә ашырыла.
4. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм җирлек Уставы нигезендә җирлек исеменнән муниципаль бурычларны гамәлгә ашыру хокукы җирлек башкарма комитетына карый.
5. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыру җирлек тарафыннан түбәндәге шартларны үтәгәндә гамәлгә ашырыла:
1) җирлекнең бурыч йөкләмәләре буенча кичектерелгән бурычлары булмау;
2) җирлек тарафыннан исемлекләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган рейтинг гамәлләрен тормышка ашыручы бер яисә берничә юридик заттан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган дәрәҗәдән дә ким булмаган кредит рейтингы алынган.
6. Җирлек, аны Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107.1 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31.1 статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы уртача дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә керткән очракта, муниципаль бурыч алулар башкарырга, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107.1 статьясындагы 5 пунктында каралган җирлекнең бурыч

тотрыклылыгы күрсәткечләренең зурлыгын җирлекне бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемчылар төркеменә кертергә мөмкинлек бирә торган дәрәҗәләргә кадәр арттыруга китерә торган күләмнәрдә муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы түгел.
7. Җирлек, аны Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107.1 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31.1 статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы уртача дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертүән очракта, муниципаль бурыч алулар башкарырга, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән муниципаль эчке һәм тышкы бурыч алулар программаларын, чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль гарантияләр программаларын, шулай ук күрсәтелгән программаларга үзгәрешләрне килештергән очракта гына муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы.
8. Җирлек, аны Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107.1 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31.1 статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә керткән очракта, муниципаль бурыч алулар башкарырга, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107.1 статьясындагы 5 пунктында каралган җирлекнең бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләренең зурлыгын арттыруга китерә торган күләмнәрдә муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы түгел.
9. Җирлек, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107.1 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31.1 статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемчылар төркеменә кергән очракта, муниципаль тышкы бурыч алулар башкарырга һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында бирергә хокуклы түгел.
10. Җирлек, аны Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107.1 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31.1 статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә керткән очракта, муниципаль эчке бурыч алулар башкарырга, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән муниципаль эчке бурыч алулар, чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр программаларын, шулай ук күрсәтелгән программаларга үзгәрешләрне килештергән очракта гына Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы.
11. Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107.1 статьясындагы 9 пунктында каралган җирлеккә түләү мөмкинлеген торгызу планы кысаларында бирелгән максатчан бюджет кредитлары буенча җирлек йөкләмәләренә реструктуризация үткәрү рөхсәт ителми.

## 19 статья. Җирлекнең гарантияләрне чит ил валютасында биреп, бурычка алуларны гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

1. Җирлек Россия Федерациясеннән чит ил валютасында бурыч алулар башкарырга, Россия Федерациясенә чит ил валютасында өченче затлар

йөкләмәләре буенча гарантияләрне бары тик җәлеп ителгән максатчан чит ил кредитларын Россия Федерациясе тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 статьясындагы 25 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып куллану кысаларында гына бирергә хокуклы.

## 20 статья. Муниципаль бурычка алуларның иң чик күләме

1. Тиешле финанс елына муниципаль бурыч алуларның иң чик күләме дигәндә тиешле финанс елына муниципаль эчке һәм тышкы бурыч алулар программалары буенча җирлек бюджетына акча җәлеп итүнең җыелма күләме аңлашыла.
2. Хисап финанс елында җирлекнең бурыч алуларының гомуми суммасы җирле бюджет дефицитын финанслауга юнәлтелгән акчаларның гомуми суммасыннан һәм җирлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләменнән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара трансфертлардан, максатчан билгеләнешкә ия булган юридик затлардан түләүсез керемнәрдән, җирле бюджетларга җирле бюджетларның баланслылыгын тәэмин итү чараларына ярдәм итү өчен дотацияләрдән яисщ яки Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга аларны бирү шартларын билгеләп бирелгән башка дотацияләрдән тулысынча файдаланмау сәбәпле хисап финанс елы ахырына барлыкка килгән калдыклар күләменә, шулай ук хисап финанс елының соңгы эш көненнән соң җирле бюджетка кертелгән хисап финанс елы керемнәре күләменә, шул исәптән йомгаклау әйләнешләрен үткәрү тәртибендә артыграк булырга мөмкин.
Хисап финанс елында җирлек бурыч алуларының гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның гомуми суммасыннан һәм хисап финанс елы нәтиҗәләре буенча агымдагы елның 1 гыйнварына барлыкка килгән җирлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәреннән, әлеге статьяның 2 нче пунктында каралган мөмкин булган артыклыкларны исәпкә алып, артып киткән очракта, җирле бюджет акчаларының әлеге артыклык суммасында калган өлешләре, агымдагы финанс елына бурыч алуларның иң чик күләмен кыскартып, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96 статьясында каралган максатларга юнәлдерелергә тиеш.

## 21 статья. Муниципаль эчке һәм тышкы бурычның югары чикләре һәм җирлекнең бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләренең иң чик кыйммәтләре

1. Җирле бюджет турындагы карар белән чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына (чираттагы финанс елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына) торышы буенча муниципаль эчке бурычның, муниципаль тышкы бурычның (җирлекнең чит

ил валютасындагы йөкләмәләре булганда) иң югары чикләре, шул исәптән Россия Федерациясе валютасындагы муниципаль гарантияләр, чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр (җирлекнең чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләре булганда) буенча бурычның иң югары чиген күрсәтеп билгеләнә.

2. Муниципаль эчке бурычның, муниципаль тышкы бурычның иң югары чикләре (җирлекнең чит ил валютасындагы йөкләмәләре булганда) әлеге статьяның 4 һәм 5 пунктларында билгеләнгән чикләүләрне үтәгәндә билгеләнә.

3. Муниципаль бурыч күләме, кире кайтарылмый торган түләүләрнең расланган күләмен һәм (яисә) физик затлар керемнәрәнә салымнан күчерүләрнең (отчисления) өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре кертемнәрен исәпкә алмыйча, чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында карар белән расланган җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменнән артмаска тиеш.

Җирлеккә карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясындагы 4 пунктында каралган чаралар кулланылган очракта,физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча кире кайтарылмый торган керемнәрнең һәм (яисә) салым керемнәренең расланган күләмен исәпкә алмыйча, бурыч күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында карар белән расланган җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменең 50 процентыннан артмаска тиеш.

4. Муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү чыгымнары күләме, түбәндәге таләпләрне үтәгәндә, җирле бюджет турындагы карар белән раслана:

1) Чираттагы финанс елында һәм план чорында муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү чыгымнары күләме өлеше чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы яисә чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында карар белән расланган тиешле бюджет чыгымнарының гомуми күләменең 10 процентыннан артмаска тиеш, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар күләменнән тыш;

2) чираттагы финанс елында һәм план чорында чираттагы финанс елының 1 гыйнварына барлыкка килгән муниципаль бурычны түләү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча түләүләрнең еллык суммасы чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында карар белән расланган җирле бюджетның салым, салым булмаган керемнәренең һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан дотацияләрнең гомуми күләменнән 20 проценттан артмаска тиеш; күрсәтелгән нисбәтне исәпләгәндә, Чираттагы финанс елы һәм план чорының һәр елы өчен килә торган елның 1 гыйнварыннан соң килә торган түләү вакыты белән бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда түләүгә җибәрелә торган түләүләр суммасы исәпкә алынмый.

## 22 статья. Чит ил валютасында муниципаль гарантияләр программасы

1. Чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында бирелә торган муниципаль гарантияләрнең түбәндәге белешмәләр күрсәтелгән чит ил валютасындагы исемлегеннән гыйбарәт:
1) гарантияләүнең һәр юнәлеше (максатлары), категорияләре (төркемнәре) һәм (яисә) принципаллар исемнәрен күрсәтеп, гарантияләү юнәлешләре (максатлары);
2) гарантияләр һәм алар тарафыннан тәэмин ителә торган йөкләмәләр буенча йөкләмәләр валютасы;
3) гарантияләрнең гомуми күләме;
4) гарантның принципалларга карата регресс таләбе хокукы булу (булмау);
5) гарантияләрне бирү һәм үтәүнең башка шартлары.
2. Муниципаль гарантияләр муниципаль гарантия белән тәэмин ителә торган йөкләмәләр күрсәтелгән валютада бирелә һәм үтәлә.
3. Чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр программасы бюджет турындагы тиешле карарга кушымта булып тора.

## 23 статья. Муниципаль тышкы алынмалар программасы

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль тышкы бурыч алулар программасы чираттагы финанс елына һәм план чорына максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында федераль бюджеттан чит ил валютасында җирле бюджетка җәлеп ителә торган һәм (яки) чит ил валютасында түләнелә торган бюджет кредитлары исемлегеннән гыйбарәт.
2. Муниципаль тышкы бурыч алулар программасы белән түбәндәгеләр билгеләнә:
1) җирле бюджетка акча җәлеп итү күләме һәм максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында чираттагы финанс елында һәм план чорында федераль бюджеттан чит ил валютасында җирле бюджетка җәлеп ителә торган бюджет кредитлары буенча барлыкка килә торган бурыч йөкләмәләрен каплау сроклары;
2) чираттагы финанс елында һәм план чорында, максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында федераль бюджеттан чит ил валютасында җирле бюджетка җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча барлыкка килгән җирлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләме.
3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль тышкы бурыч алулар программасы чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турындагы карарга кушымта булып тора.

## 24 статья. Муниципаль эчке бурыч алулар программасы

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль эчке бурыч алулар программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында гамәлгә ашырыла торган һәм (яисә) түләнә торган тиешле бурыч йөкләмәләре төрләре буенча муниципаль эчке бурыч алулар исемлегеннән гыйбарәт.
2. Муниципаль эчке бурыч алулар программасы белән түбәндәгеләр билгеләнә:
1) җирле бюджетка акча җәлеп итү күләме һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында тиешле бурыч йөкләмәләре төрләре буенча муниципаль эчке бурыч алуларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган бурыч йөкләмәләрен түләүнең иң чик сроклары;
2) тиешле бурыч йөкләмәләре төрләре буенча Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль бурыч йөкләмәләрен юкка чыгару күләмнәре.
3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль эчке бурыч алулар программасы чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы карарга кушымта булып тора.
4. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 105 статьясы нигезендә муниципаль эчке бурычны үткәрү муниципаль эчке бурыч алулар программасында чагылыш тапмый.

## 25 статья. Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр программасы

1. Россия Федерациясе валютасындагы муниципаль гарантияләр программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында бирелә торган муниципаль гарантияләрнең түбәндәге белешмәләр күрсәтелгән Россия Федерациясе валютасындагы исемлегеннән гыйбарәт:
1) гарантияләүнең һәр юнәлеше (максатлары), категорияләре (төркемнәре) һәм (яисә) принципаллар исемнәрен күрсәтеп, гарантияләү юнәлешләре (максатлары);
2) гарантияләрнең гомуми күләме;
3) гарантның принципалларга карата регресс таләбе хокукы булу (булмау);
4) гарантияләрне бирү һәм үтәүнең башка шартлары.
2. Россия Федерациясе валютасында белдерелгән йөкләмәләр буенча муниципаль гарантияләр бары тик Россия Федерациясе валютасында гына бирелә һәм үтәлә.
3. Россия Федерциясе валютасындагы муниципаль гарантияләр программасы бюджет турындагы карарга кушымта булып тора.»;

## 26 статья. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр урнаштыруның чик күләмнәре

Чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына муниципаль кыйммәтле кәгазьләрнең номиналь хакы буенча иң чик күләме бюджет турында карар белән билгеләнгән муниципаль эчке бурычның югары чикләре нигезендә җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

## 27 статья. Муниципаль гарантияләр

1. Муниципаль гарантия принципалның бенефициар каршында килешүдән яки башка алыш-бирештән (төп йөкләмәдән) килеп чыккан акчалата йөкләмәләрен тиешенчә үтәүне тәэмин итә.
2. Муниципаль гарантия принципал йөкләмәләрен вакытыннан алда үтәүне, шул исәптән принципалга аларны вакытыннан алда башкару турында таләпләр куелган очракта яисә принципал йөкләмәләрен үтәү срогы килеп җиткән дип санала торган вакыйгалар (хәлләр) туган очракта тәэмин итми.
3. Муниципаль гарантиянең язма формасы мәҗбүри булып тора.
4. Муниципаль гарантия төп йөкләмә суммасы белдерелгән валютада бирелә һәм үтәлә.
5. Муниципаль гарантия буенча гарант гарантия суммасы чикләрендә принципалның үзенә тәэмин ителгән йөкләмәсе буенча субсидиар җаваплылык тота.
6. Муниципаль гарантиядә түбәндәгеләр күрсәтелә:
1) гарант исеме (тиешле гавами-хокукый берәмлек – Җирлек) һәм гарант исеменнән гарантия бирүче орган исеме;
2) бенефициар атамасы;
3) принципалның атамасы;
4) тәэмин ителешенә гарантия бирелә торган йөкләмә (төп йөкләмәнең исемен, төзү датасын һәм номерын (булган очракта), төп йөкләмәнең гамәлдә булу вакытын яисә аның буенча йөкләмәләрне үтәү срогын, якларның атамаларын, төп йөкләмәнең башка мөһим шартларын күрсәтеп);
5) гарантия буенча гарант йөкләмәләре күләме һәм гарантиянең иң чик суммасы;
6) гарантия бирү нигезләре;
7) гарантиянең үз көченә керү датасы яки гарантия үз көченә керә торган вакыйга (шарт);
8) гарантиянең гамәлдә булу срогы;
9) гарантия очрагын билгеләү, гарантия үтәлеше турында бенефициар таләбен кую вакыты һәм тәртибе;
10) гарантияне кире алу нигезләре;
11) гарант тарафыннан гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү тәртибе;
12) гарантиянең тулы күләмендә яисә нинди дә булса өлешендә үтәгәндә, принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләрен тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлешендә үтәгәндә (башка нигезләр буенча туктатканда)

һәм гарантиядә билгеләнгән башка очракларда гарантия суммасын киметү нигезләре;
13) гарантияне туктату нигезләре;
14) гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый торган төп йөкләмә шартлары;
15) гарант тарафыннан бенефициарга муниципаль гарантия буенча түләнгән акчаларны каплау турында принципалга карата гарантның таләбе булу яисә булмау (гарантның принципалга карата регресс таләбе, регресс) ;
16) гарантиянең башка шартлары, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы, гарантның норматив хокукый актлары, гарант исеменнән гарантия бирүче орган актлары белән билгеләнгән белешмәләр.
7. Гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын күздә тотмаган муниципаль гарантия акцияләренең (өлешләренең) 100 проценты муниципаль гарантия бирә торган җирлеккә караган хуҗалык җәмгыяте, мөлкәте муниципаль гарантия бирә торган җирлек милкендә булган муниципаль унитар предприятие йөкләмәләре буенча гына бирелергә мөмкин, Принципал тулысынча яки өлешчә хосусыйлаштырылган очракта, мондый муниципаль гарантия принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукы белән бирелгән дип санала һәм принципалның Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115.3 статьясы һәм Россия Федерациясе граждан законнары таләпләренә туры килә торган җирлек башкарма комитеты актларында билгеләнгән срокта гарантиянең тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлешендә үтәлүенә бәйле рәвештә принципалга карата гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү бурычы барлыкка килә. Күрсәтелгән тәэмин итүне биргәнче, муниципаль гарантияне үтәү рөхсәт ителми.
8. Муниципаль гарантиянең үз көченә керүе календарь дата белән яисә гарантиядә күрсәтелгән билгеле бер вакыйга (шартлар) башлану белән билгеләнә.
9. Гарант бенефициарның алдан язма ризалыгыннан башка муниципаль гарантия шартларын үзгәртергә хокуклы түгел.
10. Муниципаль гарантия буенча бенефициарның гарантка карата таләп хокуклары гарантның алдан язмача ризалыгыннан башка тапшырылырга (башка нигезләр буенча күчәргә) мөмкин түгел, яңа хуҗага (сатып алучыга) алар буенча принципал (эмитент) йөкләмәләрен үтәү муниципаль гарантия белән тәэмин ителә торган облигацияләргә хокуклар күчүгә бәйле рәвештә күрсәтелгән таләп хокукларын кыйммәтле кәгазьләр турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырудан (күчү) тыш.
11. Муниципаль гарантия гарантиядә күрсәтелгән очракларда һәм нигезләр буенча (шул исәптән әлеге статьяның 6 пунктының 14 булегендә күрсәтелгән төп йөкләмә шартлары гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәргән очракта), шулай ук әлеге статьяның 7 пунктында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115.3 статьясының 5 пунктында билгеләнгән бурычны принципал үтәмәгәндә Гарант тарафыннан кире алына.

12. Бенефициарның муниципаль гарантия буенча акча түләү турындагы таләбе (гарантияне үтәү турында бенефициар таләбе) гарантка гарантиядә билгеләнгән очракта гына (гарантия очрагы килеп туганда) бирелергә мөмкин. Гарантияне үтәү турында бенефициар таләбе гарантиядә билгеләнгән тәртиптә, гарантиядә күрсәтелгән документларны кушып, гарантка язмача тапшырылырга тиеш.
13. Бенефициар муниципаль гарантия һәм муниципаль гарантия бирү турында шартнамә белән билгеләнгән срогыннан алда, шул исәптән, принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләрен үтәү срогы килеп җиткән дип исәпләнә торган вакыйгалар (шартлар) туган очракта гарантияне үтәү турында таләпләр куярга хокуклы түгел.
14. Гарант гарантия үтәлеше турында бенефициарның таләп кую турында принципалга хәбәр итәргә һәм принципалга таләпнең күчермәсен тапшырырга бурычлы.
15. Гарант муниципаль гарантиядә билгеләнгән срокта гарантияне үтәү турында бенефициар таләбен таләпнең һәм аңа кушып бирелгән документларның нигезлелеге һәм гарантия шартларына туры килү-килмәве предметы буларак күрсәтелгән таләпкә кушымта итеп бирелгән документлар белән бергә карарга тиеш.
16. Гарантияне үтәү турында бенефициар таләбе һәм аңа кушып бирелгән документлар нигезсез һәм (яисә) гарантия шартларына туры килми дип танылa, һәм гарант бенефициарга түбәндәге очракларда аның таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тарта:
1) таләп һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар гарантка гарантиянең бирелгән срогы (гарантиянең гамәлдә булу срогы) тәмамланганнан соң тапшырылган;
2) таләп һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар гарантка гарантиядә билгеләнгән тәртипне бозып тапшырылган;
3) таләп һәм (яки) аңа кушып бирелгән документлар гарантия шартларына туры килми;
4) бенефициар принципалның принципал һәм (яки) өченче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән принципал йөкләмәләрен тиешенчә үтәүдән баш тарта;
5) әлеге статьяның 7 пунктында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1153 статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән очракта;
6) гарантиядә билгеләнгән башка очракларда.
17. Гарантия үтәлеше турында бенефициар таләбе һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар нигезсез һәм (яисә) муниципаль гарантия шартларына туры килми дип танылган очракта, гарант бенефициарга аның таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартуы турында хәбәр итәргә бурычлы.
18. Гарант бенефициар таләбенә каршы принципал тәкъдим итәргә мөмкин булган каршылыклар белдерергә хокуклы. Гарант, принципал алардан баш тарткан яки үз бурычын таныган очракта да, әлеге каршылыкларга хокукын югалтмый.
19. Гарантия үтәлеше турында бенефициар таләбе һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар нигезле һәм муниципаль гарантия шартларына туры

килә дип танылган очракта, гарант гарантия белән билгеләнгән вакытта гарантия буенча йөкләмәне үтәргә тиеш.
20. Гарантның бенефициар алдындагы муниципаль гарантиядә каралган бурычы принципалның гарантия белән тәэмин ителгән срогы чыккан йөкләмәләре күләмендә, әмма гарантия суммасыннан да артмаган күләмдә акча түләү белән чикләнә.
21. Муниципаль гарантия буенча бенефициар каршында гарантның бурычы туктатыла:
1) гарант тарафыннан бенефициарга гарантиядә билгеләнгән күләмдә акча түләү белән;
2) гарантиядә ул бирелгән билгеле бер вакыт (гарантиянең гамәлдә булу срогы) үткәннән соң;
3) принципал һәм (яисә) өченче затлар тарафыннан гарантия белән тәэмин ителгән принципал йөкләмәләрен үтәү йә принципалның күрсәтелгән йөкләмәләре башка нигезләр буенча туктатылган очракта (бенефициар тарафыннан гарантка һәм (яисә) судка бирелгән гарантия үтәлеше турында гарантка карата таләпләр булуга карамастан);
4) бенефициарның гарантка аны кире кайтару юлы белән гарантия буенча үз хокукларыннан баш тартуы һәм (яисә) бенефициарның гарантны гарантия буенча үз вазыйфаларыннан азат итү турында язма гаризасын бирү нәтиҗәсендә, мондый гарантия буенча бенефициарлар фактта булмаганда һәм киләчәктә алар барлыкка килү өчен нигезләр булмаганда, принципал тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1151 статьясында каралган гарантияне гарантка кире кайтару нәтиҗәсендә;
5) әгәр аңгы тәэмин итүгә гарантия бирелгән принципал йөкләмәсе билгеләнгән срокта барлыкка килмәсә;
6) төп йөкләмәне (шул исәптән, бенефициар гарантка һәм (яки) судка гарантияне үтәү турындагы гарантка таләп биргәннән соң, принципалны һәм (яки) бенефициарны бетерү белән бәйле рәвештә) туктату яисә аны гамәлдә булмаган алыш-биреш дип тану белән;
7) гарантия буенча бенефициарның гарантка карата таләп хокукларын, төп бурыч буенча хокук һәм (яки) бурычларны бенефициар башка нигезләр буенча гарантның алдан язма ризалыгыннан башка бүтән затка тапшырган яки икенче затка күчкән очракт (яңа хуҗага (сатып алучыга) алар буенча принципал (эмитент) йөкләмәләрен үтәү муниципаль гарантия белән тәэмин ителә торган облигацияләргә хокуклар күчүгә бәйле рәвештә күрсәтелгән таләп хокукларын (хокук һәм бурычлар) кыйммәтле кәгазьләр турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырудан (күчү) тыш).
8) принципал тарафыннан төп бурыч буенча принципалга караган хокуклар һәм (яисә) бурычлар (долг) гарантның алдан язма ризалыгыннан башка бүтән затка тапшырылган яисә башка нигезләр буенча икенче затка күчкән очракта;
9) , гарантиядә күрсәтелгән очракларда һәм нигезләр буенча гарантияне кире алу нәтиҗәсендә;
10) гарантиядә билгеләнгән башка очракларда.

22. Гарантның аның буенча йөкләмәләре туктатылганнан соң бенефициарның гарантияне тотып калуы бенефициарда күрсәтелгән гарантия буенча нинди дә булса хокуклар сакламый.
23. Муниципаль гарантияне туктату турында мәгълүм булган гарант бу хакта бенефициарга һәм принципалга хәбәр итәргә тиеш.
Муниципаль гарантияне кире алу яисә туктатуга китерә торган хәлләр килеп чыгу турында мәгълүм булган Бенефициар һәм принципал бу хакта гарантка хәбәр итәргә тиеш.
24. Әгәр гарант тарафыннан муниципаль гарантияне үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китерсә йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка юл куелуга бәйле булса, мондый муниципаль гарантияне үтәү өчен акчалар тиешле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларында исәпкә алына, ә мондый муниципаль гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү бюджет кредиты бирү буларак карала.
25. Әгәр гарант тарафыннан муниципаль гарантияне үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китермәсә йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка юл куелуга бәйле булмаса, мондый муниципаль гарантияне үтәү өчен акчалар тиешле бюджет чыгымнарында исәпкә алына.
26. Гарант тарафыннан гарантия буенча йөкләмәләрнең тулы күләмендә яисә нинди дә булса өлешендә үтәү өчен гарант тарафыннан түләнгән акчалар регрессы тәртибендә Гарант тарафыннан алынган акчалар яисә гарантка бенефициарның принципалга Карата таләбе хокукын үтәү йөзеннән Гарант тарафыннан алына торган акчалар бюджет кредитларын кире кайтару буларак чагылдырыла.
27. Муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар һәм заемнар максатчан булырга тиеш.
28. Муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән кредит (заем) акчаларыннан максатсыз файдалану факты ачыкланган очракта, муниципаль гарантия бирү турында килешүдә билгеләнгән йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, принципал һәм бенефициар Россия Федерациясе законнарында, муниципаль гарантия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән җаваплылык тоталар.
29. Бенефициарлар билгесез затлар даирәсе булган йөкләмәләрне тәэмин итүгә бирелә торган муниципаль гарантия үзенчәлекләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.
30. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясе нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча муниципаль гарантияләрне бирү һәм үтәү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.
31. Муниципаль гарантияләрне бирү тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның нигезендә кабул ителгән әлеге Нигезләмә белән билгеләнә.

## 28 статья. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр

1. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр дип җирлек исеменнән чыгарылган кыйммәтле кәгазьләр танылa.
2. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмитенты булып җирлек Уставы белән муниципаль бурыч алулар башкару хокукына ия булган җирлек башкарма комитеты тора.
3. Җирлек тарафыннан чыгарылырга мөмкин булган муниципаль кыйммәтле кәгазьләр төрләре һәм аларның эмиссиясе, һәм алар белән эш итү тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.

## 29 статья. Район бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертларның формалары.

Район бюджетыннан бюджетара трансфертлар түбәндәге формаларда бирелә:
муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр;
Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясында билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр;
башка бюджетара трансфертлар.
Җирле бюджетлардан финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр, субвенцияләр һәм максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансфертлар тора торган бюджетара трансфертлар бирү максатлары, тәртибе һәм шартлары, Татарстан Республикасы законнары һәм (яисә) башка норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителгән җирлек Советы карарлары белән билгеләнә.

## 30 статья. Татарстан Республикасы бюджетына җирлек бюджетыннан субсидияләр

1. Җирлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясында билгеләнгән тәртиптә бирелә.
2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бюджетара субсидияләр Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы нигезендә җирлек бюджетында карала.

## 31 статья. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына җирлек бюджетыннан субсидияләр

1. Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләренә туры китереп кабул ителә торган җирлек Советы карарларында каралган очракларда һәм тәртиптә башка муниципаль берәмлекләр бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында җирлек бюджетыннан субсидияләр бирелергә мөмкин.

2. Әлеге статьяда күрсәтелгән субсидияләрне бирү максатлары һәм шартлары җирлек Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары арасында төзелгән килешүләр белән билгеләнә.

## 32 статья. Җирлек бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар

Җирлек Советының таләпләр нигезендә кабул ителә торган карарларында каралган очракта һәм тәртиптә Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Бюджет кодексы Татарстан Республикасы һәм аларга туры килә торган Татарстан Республикасы законнары белән муниципаль берәмлекләр бюджетларына җирлек бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар, шул исәптән төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга бюджетара трансфертлар бирелергә мөмкин.

## 33 статья. Җирлек алдында акчалата йөкләмәләр

1. Җирлек каршындагы акчалата йөкләмәләр буенча бурыч – бурычлы кеше җирлек каршындагы акчалата бурычлары нигезендә билгеле бер датага түләргә тиеш булган акчалар суммасы.
2. Җирлек каршында акчалата йөкләмәләр буенча таләпләр җирлек финанс активларын формалаштыра.
3. Җирлек каршында акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны исәптән төшерү һәм торгызу кагыйдәләре (нигезләре, шартлары һәм тәртибе), Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очраклардан тыш, финанс-органы тарафыннан билгеләнә.
4. Җирлек алдында акчалата йөкләмәләрне (акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны) һәм мондый йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итә торган алыш-бирешләрне исәпкә алу, шулай ук күрсәтелгән йөкләмәләр һәм алыш-бирешләр буенча таләпләрнең хокукларын гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93. 2 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән тиешле орган яисә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93.2 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән вәкаләтле зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.
5. Шартнамәдә башкача билгеләнмәгән очракта, җирлек алдында акчалата йөкләмәләр тиешле сумманы Район бюджетының бердәм счетына күчерү датасыннан алып үтәлгән булып санала.

## II бүлек ҖИРЛЕК БЮДЖЕТЫ ПРОЕКТЫН ТӨЗҮ

### 34 статья. Җирлек бюджеты проектын төзү нигезләре

1. Җирлек бюджеты проектын төзү – җирлек башкарма комитетының аерым бер өстенлеге.
Бюджет проектын турыдан-туры җирлекнең финанс органы төзи.
Бюджет проектын төзү Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның таләпләрен үтәп кабул ителгән муниципаль хокукый актлар нигезендә җирлекнең Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә һәм вакытларда гамәлгә ашырыла.
2. Җирлек бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:
- Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә юлламасы нигезләмәләренә;
- Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлеге юнәлешләрен билгели торган документларга;
- җирлекнең социаль-икътисадый үсеше фаразына;
- җирлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләренә;
- озак вакытлы чорга бюджет фаразына (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразы үзгәрешләре проекты);
- муниципаль программаларга (муниципаль программалар проектларына), күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектларына.
3. Бюджет проектын вакытында һәм сыйфатлы төзү максатларында финанс органы башка финанс органнарыннан, шулай ук дәүләт хакимиятенең башка органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан кирәкле белешмәләр алырга хокуклы.

### 35 статья. Җирлекнең социаль-икътисадый үсеше фаразы

1. Җирлекнең социаль-икътисади үсеше фаразы кимендә өч елга әзерләнә.
2. Җирлекнең социаль-икътисади үсеше фаразы җирлек башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә ел саен эшләнә. Җирлекнең социаль-икътисади үсеше фаразы башкарма комитет тарафыннан җирлек Советына бюджет проектын кертү турында карар кабул итү белән бер үк вакытта хуплана.
3. Чираттагы финанс елына социаль-икътисади үсеш фаразы план чорының параметрларын төгәлләштерү һәм план чорының икенче елы параметрларын өстәү юлы белән эшләнә.
Социаль-икътисади үсеш фаразына аңлатма язуында фараз параметрларын нигезләү, шул исәптән, фаразланган үзгәрешләрнең сәбәпләрен һәм факторларын күрсәтеп, элек расланган параметрлар белән чагыштыру китерелә.

Җирлек бюджеты проектын төзү һәм карау барышында җирлекнең социаль-икътисади үсеш фаразын үзгәртү бюджет проектының төп характеристикаларын үзгәртүгә китерә.

### 36 статья. Бюджет керемнәрен фаразлау

1. Бюджет керемнәре җирлек Советына җирлек бюджеты турында карар проекты кертелгән көнгә гамәлдә булган Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары һәм бюджет законнары, шулай ук Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм җирлек бюджетының салым булмаган керемнәрен билгели торган җирлек Советының муниципаль хокукый актлары шартларында җирлекнең социаль-икътисади үсеш фаразлары нигезендә фаразлана.
2. Җирлек Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив-хокукый актларына үзгәрешләр кертүне күздә тота торган җирле бюджет турында карар проекты җирлек Советына кертелгән көннән соң кабул ителгән җирлек бюджетының керемнәре (чыгымнары) үзгәрүгә китерә торган җирлек Советының норматив хокукый актлары җирлек Советының әлеге норматив хокукый актларының чираттагы финанс елыннан соң килүче елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча үз көченә керүе турында нигезләмәне үз эченә алырга тиеш.

### 37 статья. Җирлекнең уртача сроклы финанс планы

1. Җирлекнең уртача сроклы финанс планы дигәндә, җирлек бюджетының төп параметрларын үз эченә алган документ аңлашыла.
Җирлек бюджеты проекты чираттагы финанс елына төзелә һәм раслана торган очракта, җирлек Башкарма комитеты җирлекнең уртача сроклы финанс планын эшли һәм раслый.
2. Җирлекнең уртача сроклы финанс планы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләрен үтәп, җирлек Башкарма комитеты билгеләгән форма буенча һәм тәртиптә эшләнә.
Җирлекнең уртача сроклы финанс планы проекты Башкарма комитет тарафыннан раслана һәм җирлек Советына җирлек бюджеты проекты белән бер үк вакытта тапшырыла.
Җирлекнең уртача сроклы финанс планы күрсәткечләре һәм җирлек бюджеты проектының төп күрсәткечләре бер-берсенә туры килергә тиеш.
3. Җирлекнең расланган уртача сроклы финанс планында түбәндәге параметрлар булырга тиеш:
бюджет керемнәренең һәм чыгымнарының фаразлана торган гомуми күләме;
бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләре күләмнәре йә бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләре күләмнәре;

муниципаль берәмлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне чираттагы финанс елында һәм план чорында муниципаль берәмлекләр арасында бүлү;
салым керемнәреннән җирле бюджетларга чигерүләрнең җирлек Советының хокукый актларында билгеләнә торган (билгеләнергә тиешле) нормативлары;
бюджет кытлыгы (профициты);
чираттагы финанс елыннан соң һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына муниципаль бурычның югары чиге.
Башкарма комитет тарафыннан җирлекнең уртача сроклы финанс планының өстәмә күрсәткечләрен раслау каралырга мөмкин.
4. Җирлекнең уртача сроклы финанс планы күрсәткечләре индикатив характерда була һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлекнең уртача сроклы финанс планын эшләгәндә һәм раслаганда үзгәртелергә мөмкин.
5. Җирлекнең уртача сроклы финанс планы план чорына күрсәтелгән планның параметрларын тпараметрларны өстәү юлы белән эшләнә.
Җирлекнең уртача сроклы финанс планы проектына аңлатма язуында уртача сроклы финанс планы параметрларын нигезләү, шул исәптән, планлаштырылган үзгәрешләрнең сәбәпләрен күрсәтеп, аларны элек хупланган параметрлар белән чагыштыру китерелә.

## 38 статья. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру

1. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру җирлекнең финанс органы тарафыннан гамәлдәге һәм кабул итела торган йөкләмәләрне үтәүгә аерым билгеләнә торган тәртиптә һәм методика нигезендә гамәлгә ашырыла.
2. Бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль йөкләмәне, шулай ук аның хисап финанс елында һәм агымдагы финанс елында үтәлешен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## 39 статья. Салым чыгымнары исемлеге һәм бәяләү

1. Җирлекнең салым чыгымнары Исемлеге муниципаль программалар, шулай ук муниципаль программаларга карамаган эшчәнлек юнәлешләре буенча җирлекнең башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә төзелә.
2. Җирлекнең салым чыгымнарын бәяләү, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, ел саен җирлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.
3. Күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләре җирлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

## 40 статья. Муниципаль программалар

1. Муниципаль программалар җирлек Башкарма комитеты тарафыннан раслана.
Муниципаль программаларны тормышка ашыру сроклары җирлек башкарма комитеты тарафыннан ул билгеләгән тәртиптә билгеләнә.
Муниципаль программаларны эшләү, әлеге программаларны формалаштыру һәм тормышка ашыру турында карарлар кабул итү тәртибе җирлек Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән билгеләнә.
2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә бюджет чыгымнарының һәр программага туры килә торган максатчан статьясы буенча бюджет турында карар белән раслана.
Чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалар, шулай ук элегрәк расланган җирлек Башкарма комитеты билгеләгән срокларда расланырга тиеш.
Муниципаль программалар бюджет турындагы карар белән аның үз көченә кергән көненнән ике айдан да соңга калмыйча туры китерелергә тиеш.
3. Һәр муниципаль программа буенча ел саен аны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү үткәрелә. Күрсәтелгән бәяләүне үткәрү тәртибе һәм аның критерийлары җирлек Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.
Күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләре буенча җирлек Башкарма комитеты тарафыннан чираттагы финанс елыннан башлап элек расланган муниципаль программаны туктату яисә үзгәртү, шул исәптән муниципаль программаны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләмен үзгәртү кирәклеге турында карар кабул ителергә мөмкин.

## 41 статья. Җирлек бюджет проектын төзү тәртибе һәм сроклары

1. Җирлек бюджеты проектын төзү тәртибе һәм сроклары, бюджет законнарында һәм җирлек Советының муниципаль хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне үтәп, җирлек Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.
2. Җирлек бюджеты проекты муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә гавами тыңлауларда каралырга тиеш.

# III бүлек БЮДЖЕТ ТУРЫНДАГЫ КАРАР ПРОЕКТЫН КАРАУ ҺӘМ РАСЛАУ

## 42 статья. Бюджетны карау һәм раслау нигезләре

1. Җирлек бюджеты турындагы карарда бюджетның төп характеристикалары булырга тиеш, аларга бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты (профицит), шулай ук Россия Федерациясе

Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы законнары, җирлек Советының муниципаль хокукый актлары (бюджет турында карарлардан тыш) белән билгеләнгән башка күрсәткечләр керә.

2. Бюджет турындагы карар белән түбәндәгеләр раслана:

- бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеге;
- бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге;
- бюджет ассигнованиеләрен чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемчәләре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча йә чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча һәм (яисә) максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча, шулай ук тиешенчә Россия Федерациясе Бюджет Кодексында, җирлек Советы карары белән билгеләнгән очракларда бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча да чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бүлү;
- чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет чыгымнарының ведомство структурасы;
- гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;
- Чираттагы финанс елында (чираттагы финанс елында һәм план чорында) Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына башка бюджетлардан алына торган һәм (яисә)бирелә торган бюджетара трансфертлар күләме;
- чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет расланган очракта план чорының беренче елына шартлы рәвештә раслана торган (расланган) чыгымнарның гомуми күләме бюджет чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 2,5 проценты күләмендә (Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбенә каралган максатчан билгеләнеше булган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча), план чорының икенче елына бюджет чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 5 проценты күләмендә (Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбенә каралган максатчан билгеләнеше булган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча);

чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет чыгымнары кытлыгын финанслау чыганаклары;

- чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның иң югары чиге һәм (яки) муниципаль тышкы бурычның иң югары чиге, муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиген күрсәтеп;
- җирлек бюджетының Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, җирлек советының хокукый актлары белән билгеләнгән башка күрсәткечләре.

3. Җирлек бюджеты турындагы карар проекты расланган бюджетның план чоры параметрларын үзгәртү һәм аларга җирлек бюджеты проектының план чорының икенче елы параметрларын өстәү юлы белән раслана.
Җирлек бюджетының план чоры параметрларын үзгәртү җирлек Советының муниципаль хокукый акты нигезендә гамәлгә ашырыла.
4. Шартлы рәвештә раслана торган (расланган) чыгымнар дигәндә бюджет чыгымнарының ведомство структурасында план чорында бүлекләр, бүлекчәләр, максатчан статьялар һәм чыгымнар төрләре буенча бүленмәгән бюджет ассигнованиеләре аңлашыла.
5. Шартлы рәвештә раслана торган (расланган) чыгымнар дигәндә бюджетлар чыгымнары классификациясе нигезендә план чорында бүленмәгән бюджет ассигнованиеләре аңлашыла.

### 43 статья. Бюджеты проекты белән бер үк вакытта төзелә торган документлар һәм материаллар

Җирлек бюджеты турындагы карар проекты белән бер үк вакытта җирлек Советына түбәндәгеләр тапшырыла:
- җирлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;
- агымдагы финанс елының узган чорында җирлекнең социаль-икътисади үсешенең якынча нәтиҗәләре һәм агымдагы финанс елында җирлекнең социаль-икътисади үсешенең көтелгән нәтиҗәләре;
- җирлекнең социаль-икътисади үсеше фаразы;
- чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлек берләштерелгән бюджетының төп характеристикалары (бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның, дефицитның (профицитның) гомуми күләме) фаразлары;
- җирлек бюджеты проектына аңлатма язуы;
- бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикалар проектлары) һәм исәп-хисаплары;
- чираттагы финанс елыннан соң һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның югары чиге;
- агымдагы финанс елына бюджетының көтелгән үтәлешен бәяләү;
- күрсәтелгән бюджет сметаларына карата җирлек Советы, җирлек Ревизия комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән, җирлек Башкарма комитеты белән фикер каршылыклары килеп чыккан очракта бирелә торган әлеге органнарның бюджет сметалары проектлары;
- Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексында һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән башка документлар һәм материаллар.
Муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү бюджет турында карар белән расланган очракта, бюджет турындагы карар проектына муниципаль программалар паспортлары тапшырыла.
Бюджет турында карар проектында бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү белән

кушымта булмаган очракта, бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү белән кушымта бюджет турында карар проектына аңлатма язуына кушымталар составына кертелә.

## 44 статья. Бюджет турындагы карар проектын җирлек Советына кертү

1. Җирлек башкарма комитеты бюджет турындагы карар проектын 15 ноябрьдән дә соңга калмыйча җирлек Советына карауга кертә.
2. Җирлек Советының чираттагы финанс елында һәм план чорында үз көченә керә торган җирле салымнар турындагы муниципаль хокукый актларга үзгәрешләр кертү турындагы карарлары, җирлек Советының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган, җирлек бюджеты керемнәрен үзгәртүгә китерә торган карарлары Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында карар проекты җирлек Советының муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән срокларда җирлек Советына кертелгән көнгә кадәр кабул ителергә тиеш.
3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы карар проектында расланган план чоры бюджеты күрсәткечләрен төгәлләштерү һәм төзелә торган бюджетның план чорының икенче елы күрсәткечләрен раслау күздә тотыла.
Агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы карарның план чорына караган өлешендәге нигезләмәләре 47 статьяның 3 пункты нигезендә үз көчләрен югалткан дип танылган очракта, чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турында карар проекты чираттагы финанс елы һәм төзелә торган бюджетның план чоры күрсәткечләрен раслауны күздә тота.

## 45 статья. Бюджет турындагы карар проектын җирлек Советы тарафыннан карау

1. Җирлек бюджеты турындагы карар проектын җирлек Советына керткән көннән алып 3 эш көне эчендә җирлек башлыгы аны, экспертиза үткәрү өчен, районның Контроль-хисап палатасына җибәрә.
Бюджет турында карар проекты хакындагы бәяләмә, әлеге проектның җитешсезлекләрен күрсәтеп, алар ачыкланган очракта, 5 эш көне дәвамында әзерләнә.
Бәяләмә җирлек Советы депутатлары тарафыннан җирлек бюджеты турындагы карар проектына төзәтмәләр әзерләгәндә исәпкә алына.
2. Бюджет турында кертелгән карар проекты, шулай ук районның Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе карауга җирлек Советының даими комиссиясенә, шулай ук җирлек Советы депутатларына җибәрелә.
3. Җирлек бюджеты турындагы карар проекты барлык кирәкле документлар һәм материаллар белән бергә җирлек Башкарма комитеты тарафыннан җирлек

Советына эшләп бетерүгә кергән көннән алып өч эш көне эчендә тапшырылырга тиеш.
4. Җирлек бюджеты турындагы карар проектын җибәргәннән соң бер атна эчендә җирлек Советы җирлек бюджеты турындагы карар проектын беренче укылышта карый.
Беренче укылыш предметы булып җирлек бюджеты турындагы карар проектының төп параметрларын хуплау тора.
Җирлек бюджеты турындагы карар проекты буенча беренче укылыш үткәрелгәннән соң, ике атна эчендә гавами тыңлаулар уздырыла.
5. Икенче укылышта җирлек бюджеты турындагы карар проекты тулысынча кабул ителә.
Җирлек бюджеты турындагы карар проекты буенча килешенмәгән сораулар килеп туган очракта, җирлек Советы рәисе карары белән тигез санда җирлек Башкарма комитеты һәм җирлек Советы вәкилләре кергән килештерү комиссиясе төзелергә мөмкин.
Килештерү комиссиясе бәхәсле мәсьәләләрне беренче һәм икенче укылышлар арасындагы чорда карый.
6. Җирлек бюджеты турында кабул ителгән карар кабул ителгән көннән алып өч көн эчендә имзалана һәм җирлек Уставында билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерелә.
Җирлек бюджеты турындагы карар, аңа имза салынганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча, билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

## 46 статья. Бюджет турында карарны раслау сроклары һәм бюджет турында карар проектын вакытында кабул итмәү нәтиҗәләре

1. Бюджет турындагы карар җирлек Советы тарафыннан каралырга, расланырга һәм чираттагы финанс елы башланганчы имзаланырга тиеш.
Җирлекнең җирле үзидарә органнары бюджет турындагы карарны үз вакытында карауны, раслауны, имзалауны һәм бастырып чыгаруны тәэмин итү буенча үз компетенцияләре чикләрендә мөмкин булган барлык чараларны күрергә тиеш.
Район бюджеты турындагы карар, әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм (яисә) җирлек бюджеты турындагы карарда башкасы каралмаган булса, 1 гыйнвардан үз көченә керә һәм финанс елының 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
2. Бюджет турындагы карар финанс елы башыннан үз көченә кермәгән очракта, Россия Федерациясе Бюджет кодексы билгеләгән кысаларда бюджет белән вакытлыча идарә итү режимы кертелә.

## 47 статья. Җирлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү

1. Җирлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карар проекты җирлек Советы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 45 статьясында

каралган тәртиптә һәм әлеге статьяда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып карала.
Җирлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карар проекты Совет тарафыннан бер укылышта карала.
3. Җирлекнең агымдагы финанс елында социаль-икътисадый үсешенең көтелә торган йомгаклары нигезендә җирлек бюджеты кеременең агымдагы финанс елына фаразлана торган гомуми күләме күрсәтелгән керемнәрнең агымдагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджетында каралган күләме белән чагыштырганда 15 проценттан артыкка кимегән очракта яисә Кукмара муниципаль районы бюджетына, Татарстан Республикасы бюджетына план чорына кагылышлы нигезләмәләрнең үз көчләрен югалтуын тануны күздә тота торган үзгәрешләр кертелгән очракта, җирлек бюджетының план чорына караган өлешендәге нигезләмәләре үз көчләрен югалткан дип танылырга мөмкин.

## IV бүлек ҖИРЛЕК БЮДЖЕТЫ ҮТӘЛЕШЕ

### 48 статья. Бюджет үтәлеше нигезләре

1. Җирлек бюджеты үтәлеше җирлек Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
2. Бюджет үтәлешен оештыру җирлекнең финанс органына йөкләнә.
3. Бюджет җыелма бюджет язмасы һәм касса планы нигезендә оештырыла.
Җирлек бюджеты касса бердәмлеге һәм чыгымнарның ведомство буйсынуы нигезендә башкарыла.
Бюджет үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү казначылык органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.
4. Җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җирлек Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә һәм җирлек бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә,бүлүчеләргә һәм алучыларга җиткерелә.

### 49 статья. Җирлек бюджетының керемнәр буенча үтәлеше:

Җирлек бюджетының керемнәр буенча үтәлеше түбәндәгеләрне күз алдында тота:
- җирлек бюджетына агымдагы финанс елында гамәлдә булган бюджет законнары, бюджет турындагы карар һәм Татарстан Республикасының башка законнары һәм бюджет законнары нигезләмәләре нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән нормативлар буенча бүленә торган салымнарны, җыемнарны һәм башка керемнәрне бүлүдән Федераль казначылык органнары счетларыннан һәм җирлек бюджетына бүтән кертемнәрдән керемнәр бюджетының бердәм счетына күчерү;
- артык бүленгән суммаларны күчерү, артык түләнгән яки артык алынган суммаларны, шулай ук мондый кире кайтаруны үз вакытында башкармаган

өчен процент суммаларын һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентларны кире кайтару;
- Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә артык түләнгән яисә артык түләтелгән суммаларны исәпкә алу;
- җирлек бюджеты керемнәре администраторы тарафыннан җирлек бюджетына түләүләрне төгәлләштерү.

## 50 статья. Җирле бюджетның чыгымнар буенча үтәлеше

1. Җирлек бюджетының чыгымнар буенча үтәлеше түбәндәгеләрне күздә тота:
- бюджет йөкләмәләрен кабул итү;
- акча йөкләмәләрен раслау;
- акча йөкләмәләрен түләүне санкцияләү;
- акча йөкләмәләренең үтәлешен раслау.

Бюджет акчаларын алучы бюджет йөкләмәләрен аңа җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә кабул итә.

Бюджет акчаларын алучы бюджет йөкләмәләрен кабул итә һәм элек кабул ителгән бюджет йөкләмәләренә физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән муниципаль контрактлар, башка шартнамәләр төзү юлы белән яисә закон нигезендә башка хокукый акт, килешү нигезендә үзгәрешләр кертә.

2. Бюджет акчаларын алучы бюджет акчалары исәбеннән түләү һәм аларны түләүне санкцияләү өчен кирәкле башка документлар нигезендә акча йөкләмәләрен түләү бурычын раслый.

3. Акча йөкләмәләрен түләүне санкцияләү җирлекнең финанс органы тарафыннан бюджет законнары нигезләмәләре нигезендә билгеләнгән акча йөкләмәләрен түләүне санкцияләү тәртибендә каралган документлар булу-булмавын тикшергәннән соң рөхсәт язуы (акцепт) рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Акчалата йөкләмәләрне түләү (гавами норматив йөкләмәләр буенча акчалата йөкләмәләрдән тыш) бюджет акчаларын алучыга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Акчалата йөкләмәләрне үтәүне раслау физик һәм юридик затлар, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары файдасына бюджетның бердәм счетыннан акча күчерүне раслый торган түләү документлары, шулай ук бюджет акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләрен үтәү буенча акчалата булмаган операцияләр уздыруны раслый торган башка документларны тикшерү нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 51 статья. Бюджетара трансфертлар

Җирлек бюджетыннан түбәндәге рәвешләрдә бюджетара трансфертлар бүленергә һәм (яисә) җирлек бюджетына бирелергә мөмкин:

Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 133 һәм 140 статьяларында билгеләнгән очракларда шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына муниципаль районнар бюджетларыннан субвенция;;
Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.2 статьясында билгеләнгән очракларда Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр;
җирлекнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Кукмара муниципаль районы бюджетыннан дотацияләр;
муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр;
башка бюджетара трансфертлар.

## 52 статья. Агымдагы финанс елы тәмамлану

1. Җирлек бюджетын үтәү буенча операцияләр, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән операцияләрдән тыш, 31 декабрьдә тәмамлана.
Агымдагы финанс елында җирлек бюджетын үтәү буенча операцияләрне төгәлләү Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә җирлекнең финанс органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.
2. Бюджет ассигнованиеләре, бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм агымдагы финанс елындагы финанслауның иң чик күләмнәре 31 декабрьдә үз көчен югалта.
3. Җирлек бюджетының бердәм счетында булмаган бюджет акчаларының бюджет акчаларын алучылар тарафыннан кулланылмаган калдыклары агымдагы финанс елының соңгы ике эш көненнән дә соңга калмыйча җирлек бюджетының бердәм счетына бюджет акчаларын алучылар тарафыннан күчерелергә тиеш.
4. Агымдагы финанс елында кулланылмаган, максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертлар алар бирелгән бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.
Бюджет акчаларының баш администраторының субсидияләр рәвешендә алынган бюджетара трансфертлар һәм максатчан билгеләнештәге бүтән бюджетара трансфертлар формасында алынган, агымдагы финанс елында файдаланылмаган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турында карары нигезендә күрсәтелгән бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдә акчалар чираттагы финанс елында алар элек бирелгән бюджет керемене, күрсәтелгән бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган бюджет чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен кире кайтарылырга мөмкин.
Максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыгы тиешле бюджет керемене күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан

билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, финанс органы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә, алар бирелгән бюджет керемenә алынырга тиеш.

## V бүлек БЮДЖЕТ ХИСАБЫН ТӨЗҮ, ТЫШКЫ ТИКШЕРҮ, КАРАУ ҺӘМ РАСЛАУ НИГЕЗЛӘРЕ

### 53 статья. Бюджетны исәпкә алу һәм хисап нигезләре

1. Бюджет хисабы үз эченә түбәндәгеләрне ала:
1) бюджет үтәлеше турында хисап;
2) бюджет үтәлеше балансы;
3) эшчәнлекнең финанс нәтиҗәләре турында хисап;
4) акча хәрәкәте турында хисап;
5) аңлатма язуы.
2. Бюджет үтәлеше турындагы хисапта Россия Федерациясе бюджет классификациясе нигезендә керемнәр, чыгымнар һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет үтәлеше турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

Бюджет үтәлеше балансы җирлек финанс һәм финанс булмаган активлары, хисап чорының беренче һәм соңгы көненә бюджет исәбе счетлары планы буенча йөкләмәләр турында мәгълүматларны үз эченә ала.

Эшчәнлекнең финанс нәтиҗәләре турында хисабы хисап чорында эшчәнлекнең финанс нәтиҗәләре турында мәгълүматны үз эченә ала һәм дәүләт идарә секторы операцияләрен классификацияләү кодлары буенча төзелә.

Акчалар хәрәкәте турындагы хисап дәүләт идарәсе секторы операцияләрен классификацияләү кодлары буенча бюджетлар акчалары белән операцияләрне чагылдыра.

Аңлатма язуында бюджет үтәлеше турында Россия Федерациясе Финанс министрлыгының норматив хокукый актларында билгеләнгән мәгълүматны ачуга таләпләр нигезендә бюджет үтәлеше турында хисапта бирелгән мәгълүматны тулыландыра торган мәгълүмат була.

3. Җирлекнең бюджет хисабы бюджет акчаларының тиешле баш администраторларының бюджет хисабы нигезендә финанс органы тарафыннан төзелә.

4. Җирлекнең бюджет хисабы еллык була. Җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап квартал саен була.

5. Җирлекнең бюджет хисабы җирлекнең финанс органы тарафыннан җирлекнең Башкарма комитетына тапшырыла.

Агымдагы елның беренче кварталы, ярты еллыгы һәм тугыз ае өчен җирлек бюджеты үтәлеше турындагы хисап җирлек башкарма комитеты тарафыннан раслана һәм җирлек Советына һәм районның Контроль-хисап палатасына җибәрелә.

Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисап җирлек Советы карары белән расланырга тиеш.

## 54 статья. Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү

1. Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисап, җирлек Советында аны караганчы, бюджет средстволары баш администраторының бюджет хисабын тышкы тикшерүне һәм җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләүне үз эченә ала торган тышкы тикшерү узарга тиеш.
2. Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләрен үтәп һәм федераль законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, җирлек Советының муниципаль хокукый актында билгеләнгән тәртиптә Район Контроль-хисап палатасы тарафыннан башкарыла.
3. Җирлек Башкарма комитеты, агымдагы елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, аңа бәяләмә әзерләү өчен, җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап бирә. Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләү бер айдан да артмаган срокта башкарыла. Бюджет үтәлеше турындагы хисапка бәяләмә бюджет акчаларының баш администраторларының еллык бюджет хисабына тышкы тикшерү күрсәткечләрен исәпкә алып әзерләнә.
4. Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә районның Контроль-хисап палатасы тарафыннан тапшырыла һәм бер үк вакытта җирлек башкарма комитетына җибәрелә.

## 55 статья. Җирлек бюджеты үтәлеше турында хисапны җирлек Советына тапшыру

1. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап җирлек Советына агымдагы елның 1 маеннан да соңга калмыйча тапшырыла.
2. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап белән бер үк вакытта аңа бюджет үтәлешенә һәм бюджет хисабына анализ ясалган аңлатма язуы һәм муниципаль биремнең үтәлеше һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләреннән файдалануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр, бюджет үтәлеше турында карар проекты, бюджет үтәлеше турында башка бюджет хисабы, Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган башка документлар тапшырыла.
3. Җирлек Советы утырышында җирлек башлыгының (вәкаләтле затның) җирлек бюджетының үтәлеше турындагы докладьт тыңлана.
4. Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы хисапны тикшерү һәм карау йомгаклары буенча җирлек Советы җирлек бюджеты үтәлеше турындагы хисапны раслау һәм җирлек Советы тарафыннан тиешле карар кабул итү яисә җирлек бюджеты үтәлеше турындагы хисапны кире кагу турында карар кабул итә.
5. Җирлек Советы тарафыннан җирлек бюджеты үтәлеше турындагы карарны кире кагу очрагында, ул мәгълүматларны дөрес булмаган яки тулы булмаган

чагылдыру фактларын бетерү һәм бер айдан да артмаган срокта кабат тапшыру өчен кире кайтарыла.

## 56 статья. Җирлек бюджеты үтәлеше турында карар

Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы карар белән хисап финанс елы өчен җирлек бюджеты үтәлеше турында җирлек бюджеты керемнәренең, чыгымнарының һәм дефицитының (профицит) гомуми күләме күрсәтелгән хисап раслана.

Хисап финанс елында җирлек бюджеты үтәлеше турындагы карарга аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

- бюджет керемнәрен классификацияләү кодлары буенча бюджет керемнәре;
- бюджет чыгымнарының ведомство структурасы буенча бюджет чыгымнары күрсәткечләре;
- бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет чыгымнары;
- бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары күрсәткечләре;

Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы карар белән шулай ук җирлек Советының муниципаль хокукый актларында җирлек бюджеты үтәлеше турында Карар кабул итү өчен билгеләнгән башка күрсәткечләр дә раслана.

# VI бүлек МУНИЦИПАЛЬ ФИНАНС КОНТРОЛЕ

## 57 статья. Муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыручы органнар

1. Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актларның, физик затларга җирлек бюджетыннан башка түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләрне һәм йөкләмәләрне билгели торган хокукый актларның нигезләмәләрен үтәүне, шулай ук муниципаль контрактларның, җирлек бюджетыннан акчалар бирү турындагы шартнамәләрнең (килешүләрнең) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.
2. Тышкы муниципаль финанс контроле районның Контроль-хисап палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.
3. Җирлек башкарма комитеты тарафыннан эчке муниципаль финанс контроле.
4. Алдан контроль җирлек бюджетын үтәү процессында бюджет хокук бозуларын кисәтү һәм булдырмау максатларында башкарыла.
5. Алга таба контроль җирлек бюджетын үтәүнең законлылыгын, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның дөреслеген билгеләү максатларында аның үтәлеше нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

### 58 статья. Бюджет хокук бозулары өчен җаваплылык

Бюджет хокук бозулары өчен җаваплылык Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән нигезләр буенча һәм тәртиптә башлана.